*Деятельность Instagram* и Facebook* в России признана экстремистской и запрещена. Компания-владелец Meta признана в России экстремистской организацией, её деятельность запрещена.

***Э.А. Габдуллина***
Казанский (Приволжский) федеральный университет
© Э.А. Габдуллина

***Научный руководитель: В.З. Гарифуллин***
доктор филологических наук, профессор
Казанский (Приволжский) федеральный университет
© В.З. Гарифуллин

# ЯЗЫКОВЫЕ ОСОБЕННОСТИ ПЕРЕДАЧ И ПУБЛИКАЦИЙ НА СПОРТИВНУЮ ТЕМАТИКУ

# СПОРТ ТЕМАСЫНА ТАПШЫРУЛАРНЫҢ ҺӘМ ЯЗМАЛАРНЫҢ ТЕЛ-СТИЛЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация.*** *В статье анализируется использование спортивных терминов на татарском языке в телевизионных передачах, прямых эфирах интернет-ресурсов и статьях на спортивную тематику. Автором приводятся примеры удачных переводов спортивных терминов на татарский язык, а также случаи типичных ошибок, нарушающих нормы современного татарского языка. В статье также содержатся рекомендации по совершенствованию спортивной терминологии на татарском языке.*

***Ключевые слова:*** *спорт, хоккей, борьба, спортивная терминология, текст, жанр.*

**Abstract.** *This article analyzes the use of sports terms in the Tatar language in television broadcasts, live broadcasts of Internet resources and articles on sports topics. The author gives examples of successful translations of sports terms into the Tatar language, as well as cases of typical mistakes that violate the norms of the modern Tatar language. The article also contains recommendations for improving sports terminology in the Tatar language.*

***Keywords:*** *sports, hockey, wrestling, sports terminology, hockey terminology.*

Спорт – популяр, катлаулы, еш кына иҗтимагый тормышта мөһим урын алып торучы социаль күренеш. Спорт – социаль ихтыяҗлар комплексын тормышка ашыру максатыннан барлыкка килгән коммуникацияләрнең үзенчәлекле төре. Спорт текстлары өчен мәгълүматлылык, төгәллек, логика, ачыклык, объективлык, аңлаешлылык кебек үзенчәлекләр хас. Мондый текстларның барысында да аралашу өлкәсенең ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә ярдәм итә торган тел үзенчәлекләрен чагылдыру чаралары кулланыла. Бу шулай ук махсус лексика һәм терминология куллануны күздә тота.

Спорт жанры текстларын язма һәм телдән дигән бүлекләргә бүләргә була. Язма жанрлар – тренерларның хисаплары, планнар, спортчыларның интернет-блоглары, анонслар һәм игъланнар. Телдән дигәненә интервью, спорт репортажлары, хисаплар, мәкаләләр керә. Соңгы вакытта публицистикада спорт характерындагы мәкаләләр шактый популярлаша бара. Спорт журналистикасына хас булган информативлык белән беррәттән, спорт мәкаләләре тәэсир итүче функцияне дә башкара. Спорт мәкаләләрендә публицистик стиль өчен хас сыйфатлар: фразеологизмнар куллану, бәяләү һәм төрле стилистик фигуралар һәм тропларны куллану күзәтелә. Спорт публицистикасы текстлары өчен дә, башка махсус текстлар өчен дә үз стилистик үзенчәлекләре хас. Спорт өлкәсе даими рәвештә үсә, яшәү рәвешенә һәм телгә үзгәрешләр кертә, шуңа күрә спорт текстларының стилистик үзенчәлекләре күп кенә тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп итә. Яңа спорт төре барлыкка килү белән бергә яңа терминнар җыелмасы да барлыкка килә.

Россиядә спорт көнбатыш күршеләргә карап актив үсә һәм популярлаша бара. Шуңа күрә рус теленә даими рәвештә рус теле составын баетучы, спорт публицистикасын әлеге стильнең башка жанрларыннан аерып торучы терминнар өстәлә тора. Бер яктан, бу факт уңай момент булып тора, чөнки чит ил сүзләре хисабына тел бай һәм төрлерәк була, спорт публицистларының мәкаләләре дә, шушы чит тел сүзләренең төрлелеге аркасында аерым төсләргә, аерым стильгә ия була башлый.

Дөрес, язмаларда да мондый сүзләрне еш кулланырга кирәкми. Спорт тематикасына текстлар язганда, матур әдәбият стиле белән публицистик стильне дөрес итеп яраштыру зарур. Шул очракта гына уңышка ирешергә мөмкин. Нинди дә булса спорт вакыйгасы турындагы хисапта спорт терминнары артык күп булса, бу әлеге хисапны укучы өчен аңлаешсыз итә. Спорт материалларын сәнгати стильдә генә язудан да яхшы әйбер дә чыкмаячак, чөнки спорт лексикасы бөтенләй үк булмаса, ул спорт мәкаләсе булмый, ул спорт тематикасына караган текстларга гына хас йөзен, стилен югалта булып чыга.

Спорт материалларында алынма терминнарны куллануның тискәре яклары да бар. Беренчедән, бу алынмалар Көнбатыш илләренә юнәлеш бирү нәтиҗәсендә килеп чыккан. Акрынлап терминнар профессиональ сүз төшенчәсеннән читкә чыга һәм матбугатта, радио һәм телевидениедә киң кулланыла башлый, бу, һичшиксез, телебезгә куркыныч тудыра.

Икенчедән, спорт терминологиясенә караган бөтен сүз дә халыкка аңлаешлы булмаска мөмкин. Мәсәлән, инглиз телендә «тайм» сүзе «вакыт» дигәнне аңлата һәм спорт термины дип саналмый. Рус, шул ук вакытта татар теленә дә «тайм» сүзе спорт уеннарында бары период, вакыт аралыгы дигәнне аңлата, тик ул әкренләп гади сөйләмгә дә кереп бара. «Футбол таймы» урынына «футбол вакыты» дип әйтеп булмый, билгеле. Тик һәрбер туры килмәгән сүз урынына алынма сүз куллана башласак, безнең спорт терминологиясе бер урында туктап кына түгел, артка тәгәри башлаячак.

Бу проблеманы спорттагы легионерлар проблемасы белән чагыштырып булыр иде. Спорт федерацияләре, легионерлар агымын туктатыр һәм үзебезнең спортчыларга күбрәк игътибар бирер өчен, «лимит» дигән төшенчә кертте. Бу чит илдән булган берничә спортчы гына катнаша ала дигәнне аңлата. Әлбәттә, алынма сүзләр куллануга лимит кертеп булмый. Шулай да спорт журналистлары алынма сүзләрне куллануны киметеп, үзебезнең телдә булган сүзләрне күбрәк куллана башлар дигән теләктә калабыз.

Татарча спорт тапшырулары һәм язмаларында тел-стиль үзенчәлекләрен тулырак карап үтик. Мәсәлән, «Татарстан – Яңа Гасыр» телеканалында баручы «Татарча хоккей» туры

эфирларында спорт терминологиясен татарча куллануның да, тел һәм стиль чараларының төрле нечкәлекләрен күрә алабыз.

Беренчедән, «Татарча хоккей» хоккейны туры эфирда татарча шәрехли. Матчларны туры эфирда алып бару – комментаторлардан зур җаваплылык, төрле ситуацияләрдә дә югалып калмау һәм сөйләмне кора белү сәләтләрен таләп итә. Гомумән, һәрбер спорт журналисты дискурсив фикерләүгә – «текстны аңлау өчен кирәк булган тел практикасы һәм экстралингвистик факторларның, ягъни коммуникациядә катнашучылар, аларның максатлары, җитештерү һәм хәбәр кабул итү шартлары турында күзаллауларның бердәмлеге»нә ия булырга тиеш .

Тел-стиль чараларына килгәндә, «Татарча хоккей» комментаторлары сүзләрне ялгаучы «дөресен әйткәндә», «әйтик инде», «нәкъ менә», «чыннан да» дигән сүзләр кулланырга ярата. Хоккей динамика яратучы спорт төре. Шуңа күрә комментаторларның сөйләмнәрендә дә динамика чагыла. Алар еш кына хоккейчылар белән бергә кычкырып та җибәрәләр, эмоцияләрен чагылдыручы җөмләләр, сүзләр белән сөйләшәләр. Хоккейчылар көндәшләр зонасына кискен ыргылыш, капкачыга кискен һөҗүм ясасалар яки алка кертсәләр, комментаторлар бертавыштан: «Менә шулай!» дип кычкыра. Шул рәвешле алар хоккейчыларга теләктәшлек белдереп, экран аша көчләрен биреп торганнарын күрсәтәләр. Бу сүзтезмәне «Татарча хоккей» комментаторларының паразит сүзе дип тә атарга була.

Динамиканы күрсәтү өчен комментаторлар бер яки сүзле җөмләләр кулланалар. «Әйдә, әйдә!», «Астан бәр!», «Тукта!», «Әнә-әнә!», «Пас. Кагарлицкий! Кэмпфер! Тарасов! Го-о-о-л!» .

Шулай ук «Татарстан – Яңа Гасыр» телеканалында күрсәтелүче «Батырлар» тапшыруы «Татарча хоккей»дан аермалы буларак яздырылган вариантта тәкъдим ителә. «Батырлар» – эфирга сирәк чыгучы тапшыру. Хәзерге көндә тапшыру бөтенләй күрсәтелми башлады. Шулай да аның тел–стиль үзенчәлекләрен карап китү мөһим дип саныйбыз.

«Батырлар»ны да Алмаз Гафиятов алып барды. Шуңа күрә «Татарча хоккей»да булган паразит сүзләр, интонация, тавыш тембры, әлбәттә, үзгәрми. Бары тик аның тынычрак сөйләшүе, көрәшчеләрне ничек тә булса сөйләштерергә тырышуын күрергә була.

Шулай ук, алда әйтеп үтелгәнчә, бу сезонда «Яңа Гасыр» телеканалында Татарстанда узган иң зур һәм дәрәҗәле көрәш ярышларыннан репортажлар да күрсәтә башладылар. Ә туры эфир Татарстан көрәш федерациясенең ютуб каналында алып барыла. Ярымфинал һәм финал ярышларын Алмаз Гафиятов шәрехли. Кыскасы, «Яңа Гасыр» телеканалында булган спорт тапшырулары барысы да Алмаз Гафиятов белән бәйле. Шуңа күрә аның тавышы, тембры, интонациясе, еш әйтә торган сүзләренә өйрәндек тә. Мәсәлән, Муса Җәлил истәлегенә багышланган турнирда ул көрәш терминологиясе актив куллана. «Алым», «сөлгеләрне бәйләү», «балл», «чистага атты», «үлчәү авырлыгы» һәм башкалар.

«Без инде Илнар ГАЛИМОВНЫҢ җиңелеп барып та, ҖИҢӘ алганын моңа кадәр күзәттек һәм аның тагын нәрсәгә СӘЛӘТЛЕ булуын да беләбез», «БӘЙЛӘРГӘ туры киләчәк»– Алмаз Гафиятов җөмләдә кайбер сүзләргә басым ясап сөйләшергә ярата. Гадәттә, ул сүзләр мәгънә ягыннан иң мөһимнәре булып тора. Шулай ук, җөмләдә инверсияне еш куллана ул. «Бәйлибез сөлгеләрне билләргә», «Монда бүген ачыкланачак җиңүчеләр» һ.б.

Спорт темасына язучы журналистлар район җирлекләрендә дә бар. Гадәттә, район матбугатында спорт тематикасы проблематик яктан ачылмый, язмаларның күбесе яңалык, хәбәр, репортаж жанрында иҗат ителә. Аларда район спортчыларының уңышлары, спорт чараларының дәрәҗәсе турында сөйләнелә.

Спорт журналистларының тел үзенчәлекләре турында сөйләгәндә, беренчеләрдән булып, аларның спорт терминнарын һәм профессионализм булып кереп калган сүзләрне төгәл һәм камил белүе мөһим. Филология фәннәре кандидаты Е.И. Гуреева спорт терминнарын 3 төркемгә аера: спорт төрләренең исемнәре һәм төркемнәре, ярышларда катнашучыларны аңлата торган терминнар һәм техник чараларны белдерүче терминнар.

Беренче төркем – спорт төрләренең исемнәре һәм төркемчәләре. Бу төркемгә керүче терминнар актив кулланыла. «Көрәш», «хоккей», «волейбол», «баскетбол», «футбол», «йөзү» һәм башкалар.

Галимә икенче төркемгә ярышларда катнашучыларны белдерә торган терминнарны кертә. Уен кырында һәр уенчының үз вазыйфасы бар. Шул вазыйфадан чыгып, аларга атамалар

бирелгән. Иң еш һәм универсаль кулланылучы атамалар: уенчы, спортчы, җиңүче, тренер, призер һ.б.

«Динамо» составында да, «Ак Барс»лылар составында да шулай ук элек бер командалар белән бәйле хоккейчылар һәм шулай ук тренерлар да әлеге уенда катнашачак».

Татар телендә ярышларда катнашучыларны белдерә торган терминнар рус теле аша, калькалаштыру юлы белән ясала. Мисаллар китерик:

*Сезнең экраннарда «Беренче звено» егетләре иде.*

*Менә монда контрһөҗүм.*

*Сакчы (защитник) – командадагы иң мөһим уенчыларның берсе. Ул, гадәттә, капкачы мәйданының алдында уйный. Аның вазифасы – көндәш команда уенчыларын капка янына китертмәү һәм гол кертергә комачаулау*. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә сакчы сүзенә түбәндәге билгеләмә бирелә: футбол, хоккей, баскетбол һ.б. уеннарда үз командасының капкасын (боҗрасын һ.б.) саклау йөкләнгән уенчы.

*Василий Токранов исәпне тигезли һәм бу сакчы өчен бик яхшы күрсәткеч.*

*Капкачы (рус телендә голкипер, вратарь) капка янындагы мәйданда уйный. Аның вазифасы – көндәш команда уенчыларына гол кертер гә мөмкинлек бирмәү, капканы саклау. «Футбол, хоккей һ.б. спорт уеннарында капка алдын саклаган уенчы».*

*Ә иң мөһиме безнең Александр Еременко каплап торалар иде. Бу очракта Клинкамер капкачы каршында басып, аның күрәзәчелек ниндидер сыйфатларын гына калдырып, аңа комачау итте.*

Өченче төркем – техник чараларны белдерүче терминнар. Һәр спорт төренең нигезендә, җиңүгә ирешергә ярдәм итә торган, техник хәрәкәтләр ята. Сан ягыннан иң зур төркем. Техник чараларны белдерүче терминнар: оту, узу, тоткарлык, атыш, чалу, күтәреп җибәрү. Мисаллар:

*Ул инде безнең күп еллар шулай ук «Ак барс»та да капкада торган иде.*

*Бөтен дулкынлану, каушаулар артта кала, чөнки хәзер сыбызгы яңгырауга уен башланып китә.*

*Максатына ирештеләр: алка керттердек тә без.*

Алда әйтеп үтелгәнчә, спорт язмаларында һәм тапшыруларында татарча һәм калькалаштыру юлы белән ясалган

сүзләр генә кулланылмый. Спорт журналистикасында профессионализмнар һәм алынма сүзләр зур урынны алып тора.

Әдәбият белеме сүзлегендә професионализмнар һөнәрчелек сүзләре, ягъни «билгеле бер һөнәр кешеләренә хас сүзләр» дип бирелә. Һөнәрчелек сүзләре күп очракта алынма сүзләр (борт, буллит, тайм, дриблинг, захват, ВХЛ (Югары хоккей лигасы), голкипер, клинч, бэк-спин, звено, кәшәкә, либеро, бутсы, офсайд, плей-офф, проброс, алка һ.б). Мәсәлән:

Әлеге уенга ике команда да төрле турнир таблицасындагы ситуация белән килделәр.

Без исә спорт терминнарын тагын берничә төргә бүлеп карар идек. Беренчесе – рольләр буенча (хоккейчы, сакчы, һөҗүмче, хөкемдар, җанатар, капитан һ.б.). Икенче төргә экипировка һәм предметларны аңлатучы терминнар керә (алка, кәшәкә, капка, капкачы битлеге, тимераяк, тез саклагыч һ.б.). Өченчесе – хоккейның нигезен аңлатучы терминнар (урта зона, хет-трик, хоккей уены, боз өслеге, бишлек, алмашыну зонасы). Дүртенче төркем – уенның тактик һәм техник элементлар (һөҗүм, саклану, бәрү, пас һ.б.). һәм соңгы төркем – ул уен кагыйдәләрен бозуны аңлатучы терминнар (алкага аяк белән тибү, көндәшкә арттан һөҗүм итү, югары күтәрелгән кәшәкә белән уйнау, кече штраф һ.б.)

Спорт дөньясындагы күп кенә терминнар төрле телләргә тәрҗемә ителми. Шул исәптән, русча ишетергә өйрәнгән сүзләрне татарчага тәрҗемә ителгән вариантта кабул итеп тә булмый. Алмаз Гафиятов бу турыда: «Татар телендә спорт терминологиясе бөтенләй юк, эшләнелмәгән. Әдәбият, журналистика белгечләре, спорт журналистлары белән берлектә шул терминнарны әзерләп эшләдек. Татарчага турыдан-туры тәрҗемә булмагач, логик яктан якын мәгънәдәге сүзләрне кулланырга тырышабыз. Төрле кеше төрлечә әйтә, уртак фикергә килү авыр», – ди.

«Татарча хоккей»ның тел үзенчәлекләре дигәндә, беренче чиратта, рус теленнән алынган спорт терминологиясен татарчага тәрҗемә итүне алырга кирәк. Мисал өчен, татар телендә латин теленнән алынган «комментирование» дигән сүзнең тәрҗемәсе юк. Аны күп очракта «шәрехләү» дип атыйлар. Гомумән, «Татарча хоккей»да турыдан-туры тәрҗемә ителми торган сүзләрне татарчалаштыру дигән күренеш киң таралган:

«показатель полезности» – «файдалык күрсәткече», «обводка» – «әйләндереп алу», «отбор шайбы» – «алканы талау», «расстановка» – «кереп урнашу», «вбрасывание» – «алка ыргыту», «большинство» – «күпчелек», «меньшинство» – «азчылык», «точка вбрасывания» – «ыргыту ноктасы» кебек сүзләр дә шик уята.

Мисал өчен, «отбор шайбы» терминын «алканы талау» дип тәрҗемә итү мәгънә ягыннан дөрес түгел. Чөнки талау – ул рус теленнән «грабеж, разбойное нападение» дип тәрҗемә ителә. Хоккейчыларның бозда андый максатлары юк. «Отбор шайбы» ны «алканы тартып алу» дип тәрҗемә итсәк, дөресрәк булыр.

Шулай ук, «большинство»ны – күпчелек, «меньшинство»ны азчылык дип әйтү дә туры тәрҗемә, калькалаштыруга барып кала. «Большинство» – ул көндәш такымның уенчысы кагыйдә бозу аркасында штрафка тартылып, сезнең такымның бозда уенчылары сан ягыннан аларныкына караганда күбрәк булуны аңлата. Ә көндәш такым бу очракта «меньшинство»да уйный дип санала. «Азчылык», «күпчелек» кебек калькалаштыру аркасында барлыкка килгән, матур яңгырамый һәм фразеологизм белән әйткәндә, колакны яра торган сүзләр кулланмау яхшырак булыр идек. «Большинство»ны «тулы составта уйнау», ә меньшинствоны киресенчә, «тулы булмаган составта уйнау» дип әйтсәк, матур яңгырашлы һәм аңлаешлы җөмләләр килеп чыгачак.

Татар телендә спорт терминнары җыентыгы булмау телне бозу, мәгънәсе буенча туры килмәгән яңа сүзләр уйлап табуга әйләнеп калырга мөмкин. Тик, ни кызганыч, әлегә спорт терминнары сүзлеге юк, терминнар җыела башлады гына. Спортчы, комментаторлар, филология фәннәре белгечләренең бергә эшләве нәтиҗәсендә генә хоккей терминологиясен татарча дөрес тәрҗемә итеп булачак.

**Әдәбият:**

1. Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. Яр Чаллы: «КАМАЗ» нәшр., 1997. 128 б.

2. Алмаз Гафиятов: «Иң зур хыялым – Татарстанда спорт телеканалы ачу» // URL: tnv.ru (мөрәҗәгать итү вакыты: 05.04.2022).

3. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.
4. Бабаян В.Н. Дискурс как сложный коммуникативный феномен // URL: https://cyberleninka.ru/article/n/diskurs-kak-slozhnyy-kommunikativnyy-fenomen (мөрәҗәгать итү вакыты: 11.01.23).
5. Газиз Г. Хоккейны татарча алып бару уңышсыз тәмамлана // URL: https://www.azatliq.org/a/1968486.html (мөрәҗәгать итү вакыты: 11.01.23).
6. Гарифуллин В.З. Методология и технология журналистского творчества. Казань: Изд-во Казан. ун-та. 2019. 152 с.
7. Сафиуллина Ф.С. Татар телендә сүз тәртибе. Казан: Татар. китап. нәшр., 1974. 152 б.
8. Низамов И.М. Татар социолингвистикасы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2006. 152 б.
9. Сабирова Л.Р. Роль СМИ Республики Татарстан в формировании у населения интереса к физической культуре // Наука и спорт: современные тенденции. №3 (Том 20), 2018. С. 121-127.
10. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: V том: С – Т. Казан: ТӘһСИ, 2019. 908 б.
11. Фатыйхова М.Х. Татар телендәге телевизион хәбәри сөйләмнең функцияләре. Казан. 2010. 257 б.
12. Фәттахов И.Ф. Әдәбият теориясе нигезләре: журналистика факультеты студентлары өчен «Әдәбият теориясе нигезләре» дисциплинасыннан уку ярдәмлеге. Казан: К(И)ФУ нәшр., 2011. 210 б.
13. Шиһабетдинов А. Алмаз Гафиятов: «Батырлар» – халык тапшыруы!» // Шәһри Казан. 2018. 13 окт.

## Чыганаклар

1. Татарчалашкан «Ак Барс» // «ТНВ-Планета» телеканалы. 2020. 10 март. URL: https://www.youtube.com/watch?v=gS800YYkWhs&list=PLZdaI5wEay2p1_dFS9 (мөрәҗәгать итү вакыты: 11.01.2023).
2. Татарча хоккей // «ТНВ-Планета» телеканалы. 2017. 10 март. URL: https://www.youtube.com/watch?v=4sEDlPfOfp8 (мөрәҗәгать итү вакыты: 11.01.2023).

3. Татарча хоккей // «ТНВ-Планета» телеканалы. 2021. 30 ноябрь.
4. Татарча хоккей // «ТНВ-Планета» телеканалы. 2021. 3 декабрь.
5. Татарча хоккей // «ТНВ-Планета» телеканалы. 2021. 6 декабрь.
6. Татарча хоккей // «ТНВ-Планета» телеканалы. 2021. 10 декабрь.
7. Татарча хоккей // «ТНВ-Планета» телеканалы. 2021. 12 декабрь.

***Р.М. Галиева***
кандидат филологических наук
Казанский (Приволжский) федеральный университет,
© Р.М. Галиева
***А.И. Кадриева***
Казанский (Приволжский) федеральный университет
© А.И. Шакирова

# ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ГАЗЕТЫ «ШАХРИ КАЗАН» В ИНТЕРНЕТЕ

# «ШӘҺРИ КАЗАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ ИНТЕРНЕТТАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация.*** *Газета «Шәһри Казан» ведет активную деятельность в интернете. Сайт газеты «Шәһри Казан» («Город Казань» http://shahrikazan.com) начал работать в 2011 году. Здесь постоянно размещаются всевозможные новые статьи и сообщения. Новости на сайте публикуются и на страницах газеты в социальных сетях. У «Шәһри Казан» есть свои группы в социальных сетях «ВКонтакте», «Одноклассники» и др. Газета «Шәһри Казан» поддерживает тесную связь с аудиторией через сайт и социальные сети.*

***Ключевые слова:*** *сайт, социальные сети, газета, интернет, публикация, сообщение.*

***Abstract.*** *The newspaper «Shahri Kazan» is active on the Internet. Website of the newspaper «Shahri Kazan» («City Kazan» http://shahrikazan.com) has been started in 2011. All kinds of new*